**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 24 август № 616

г. Казань

Казан шәһәре, Карл Маркс урамы, 68 нче йорт адресы буенча урнашкан бина фасадына мемориаль такта кую турында

Җылылык физикасы өлкәсендә күренекле галим, 1959 – 1962 елларда С.М.Киров исемендәге Казан химия-технология институты ректоры, профессор Усманов Айтуган Гариф улы истәлеген мәңгеләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының, «Казан милли тикшеренү технология университеты» югары һөнәри белем бирүче федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең Казан шәһәре, Карл Маркс урамы, 68 нче йорт адресы буенча урнашкан бина фасадына Айтуган Гариф улы Усмановка рус һәм татар телләрендә түбәндәге текст язылган мемориаль такта кую турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

«В этом здании в 1943 – 1996 гг. работал
выдающийся ученый-теплофизик,
в 1959 – 1962 гг. ректор КХТИ, профессор
Айтуган Гарифович Усманов

---

Бу бинада 1943 – 1996 елларда
җылылык физикасы өлкәсендә күренекле галим,
1959 – 1962 елларда КХТИ ректоры, профессор
Айтуган Гариф улы Усманов эшләде».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\616.doc